СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**

**Сеҗе авыл җирлеге башлыгы карары**

**22 март 2024 ел** **№12**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегенең Ташкич авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 24 ноябрендәге 12 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегенең Ташкич авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегенең Ташкич авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 12 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегенең Ташкич авылында гражданнар җыенының беренче этабын Ташкич авылы, Х.Такташ урамы, 26 йорт адресы буенча 2024 елның 06 апрелендә 08 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегенең Ташкич авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 12 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегенең Ташкич авылында гражданнар җыенының беренче этабын Ташкич авылы, Х.Такташ урамы, 26 йорт адресы буенча 2024 елның 06 апрелендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Г.Тукай урамында яшәүчеләр

2нче этап: Х.Такташ урамында яшәүчеләр.

4. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегенең Ташкич авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 22 март 1 нче номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Ташкич авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан,1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, автоматлар, контакторлар сатып алу һәм урнаштыру);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Х.Такташ урамы һәм Г.Тукай урамы буенча юл-урам челтәрендәге автомобиль юлларына өлешчә вак таш җәю);

- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү (бензин генераторын сатып алуны финанслашу);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторының асылмалы җиһазы чапкыч өчен пычаклар комплекты сатып алуны финанслашу);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. « Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегенең Ташкич авылына гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023

елның 24 ноябрендәге 12 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Ташкич авылы, Х.Такташ урамы, 26 йорт , адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хәмидуллин